ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 сентябрь 2017 ел № 5526

«2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәт белән идарә итү системасын камилләштерү, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм муниципаль хезмәткәрләрнең профессиональ хезмәт нәтиҗәлелеген күтәрү максатында, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2008 елның 18 апрелендәге 31/13 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 11 декабрендәге 7511 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү» муниципаль программасы чараларын финанслауны шәһәр бюджетының «Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары, җирле хакимият эшчәнлеге» 01.04, «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 10849,59 мең сум: 2018 ел – 3616,53 мең сум, 2019 ел – 3616,53 мең сум, 2020 ел – 3616,53 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2017 елның 15 сентябрендәге
5526 номерлы карарына
кушымта

«2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү»
муниципаль программасы

1 бүлек. «2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү»
муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Татарстан Республикасының «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Законы;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү Дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 910 номерлы карары;<br>Шәһәр Советының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы; Шәһәр Советының 2008 елның 18 апрелендәге 31/13 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә |
| Программаның төп эшләүчесе | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе |
| Программаны башкаручылар | Башкарма комитет |
| Программаның максаты | Муниципаль хезмәт белән идарә итү системасын камилләштерү юлы белән җирле үзидарә органнары тарафыннан йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү нәтиҗәлелеген арттыру.<br>Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәттә кадрлар эшенә заманча технологияләр кертү. |
| Программаның бурычлары | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру.<br>Муниципаль хезмәткәрләрне сайлап алу, эшчәнлеген комплекслы бәяләү һәм хезмәт буенча күтәрүнең нәтиҗәле механизмнарын кертү<br>Муниципаль хезмәткә яшь, перспективалы белгечләрне җәлеп итү һәм беркетү. |

<table>
<tr><td></td><td colspan="5">Муниципаль хезмәттә коррупциягә каршы тору чараларын тормышка ашыру системасын үстерү.<br>Муниципаль хезмәткәрләрнең профессиональ һәм идарә итү компетентлылыгын үстерү.<br>Муниципаль хезмәттә мотивацияләү, стимуллаштыруның нәтиҗәле системасын төзү.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="5">2018-2020 еллар<br>«2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү» муниципаль программасын (алга таба - программа) тормышка ашыру этаплары:<br>1. 1 этап - 2018 ел;<br>2. 2 этап - 2019 ел;<br>3. 3 этап - 2020 ел.</td></tr>
<tr><td rowspan="7">Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="3">Программаны тормышка ашыру еллары (мең сум)</td><td rowspan="2">барлыгы (мең сум)</td></tr>
<tr><td>2018 ел</td><td>2019 ел</td><td>2020 ел</td></tr>
<tr><td>муниципаль бюджет</td><td>3 616,53</td><td>3 616,53</td><td>3 616,53</td><td>10849,59</td></tr>
<tr><td>республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>барлыгы</td><td>3 616,53</td><td>3 616,53</td><td>3 616,53</td><td>10849,59</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре</td><td colspan="5">Программаны тормышка ашыру 2020 елга түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>1. Җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең максатларына һәм бурычларына туры килә торган муниципаль хезмәткәрләр санын билгеләргә.<br>2. Муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын эшләргә һәм гамәлгә кертергә. Җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә муниципаль идарә органнарының йөкләнгән бурычлары һәм функцияләре кысаларында башкарыла торган процессларны тасвирлау стандартларын кертергә.<br>3. Яр Чаллы шәһәре социаль-икътисадый үсешенең өстенлекле юнәлешләрен исәпкә алып, муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирүне оештырырга.<br>4. Муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү системасын һәм социаль ярдәм чараларын камилләштерергә, ел саен үткәрелә торган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль идарә өлкәсендә иң яхшы хезмәткәре» конкурсын үткәрү тәҗрибәсен кертергә.<br>5. Муниципаль хезмәткә яшь, перспективалы белгечләрне җәлеп итәргә, шул исәптән җирле үзидарә органнарында студентларның практикасын оештыру юлы белән.<br>6. Муниципаль хезмәт белән идарә итү системасына заманча</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | мәгълүмати, кадрлар технологияләр кертергә, шул исәптән дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасында кадрлар эшен алып баруны тәэмин итәргә. Муниципаль хезмәткәрләрнең эш урыннарын заманча җиһазлар белән җиһазландырырга.<br>7. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең билгеләнгән төп күрсәткечләренә ирешүгә бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәрләрне матди стимуллаштыруны гамәлгә ашырырга.<br>8. Муниципаль хезмәттә коррупцияне кисәтү һәм аңа каршы көрәш чараларын өстенлекле куллануга юнәлдерелгән эшне камилләштерергә. |
| Программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы | Программаның үтәлешенә гомуми контрольне Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе гамәлгә ашыра |

## 2 бүлек. Аларны хәл итү өчен программа юнәлдерелгән проблемаларның эчтәлеге

Татарстан Республикасында гамәлгә ашырыла торган реформалар шартларында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеше белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген Яр Чаллы шәһәрендә җирле үзидарә органнарында югары профессиональ кадрлар булганда гына күтәрергә мөмкин. Халыкның хакимияткә булган ышанычы, аның уңышы һәм нәтиҗәлелеге күбесенчә җирле үзидарә органнарының ни дәрәҗәдә нәтиҗәле эшләвеннән тора.

Җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен һәм функцияләрен гамәлгә ашыру түбәндәгеләр белән билгеләнә:

1) җирле үзидарә органнары системасының, аларның функциональ-вазыйфаи структураларының торышы;

2) кадрлар составының торышы һәм, барыннан да элек, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең профессиональлеге;

3) муниципаль берәмлек халкының һәм җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге инструментлары һәм ысуллары булу.

Хәзерге заман муниципаль хезмәткәре үз вазыйфаларын нәтиҗәле башкарырга, киң белемле булырга, үз эшчәнлегендә халык мәнфәгатьләренә ориентлашырга тиеш. Җирле үзидарә органнарының кадрлар потенциалын формалаштыруның һәм үстерүнең төп юнәлешләрендә кадрлар сәясәте стратегиясенең төп юнәлешләрен билгеләргә кирәк:

1) муниципаль хезмәт кадрларының профессиональ эшчәнлеге белән идарә итү;

2) муниципаль хезмәтнең профессиональ эшчәнлеген хокукый тәэмин итү;

3) муниципаль хезмәт кадрларын әзерләү белән идарә итү.

Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтне кадрлар белән тәэмин итү өлкәсендә берничә мәсьәлә аерылып тора, аларны хәл итү түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү өчен кирәк:

1) муниципаль хезмәткә кадрлар сайлап алуның бердәм системасы булмау;

2) 30-45 яшьтәге муниципаль хезмәткәр кадрлары алмашынып тору;

3) муниципаль идарә функцияләрен гамәлгә ашыру эчтәлеге һәм шартлары үзгәрүгә бәйле рәвештә күпчелек муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри белемнәрен системалы рәвештә яңарту зарурилыгы;

4) муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри эшчәнлеген һәм эш сыйфатын бәяләү системасы булмау;

5) муниципаль хезмәткәрләргә фәнни нигезләнгән критерийлар, профессиональ таләпләр булмау.

Шул сәбәпле, муниципаль хезмәт өлкәсен модернизацияләү зарурлыгы туа. Муниципаль хезмәттә кадрлар составын көчәйтергә, муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттырырга һәм, нәтиҗә буларак, җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен киләчәктә югары нәтиҗәле башкаруны тәэмин итәргә сәләтле системалы карарлар кабул итү таләп ителә.

Программаны тормышка ашыру муниципаль хезмәт нигезләрен камилләштерергә, аларны оештыру һәм эшләтүне оптимальләштерергә, муниципаль хезмәттә заманча кадрлар, мәгълүмати, белем бирү һәм идарә итү технологияләрен кертергә мөмкинлек бирәчәк.

## 3 бүлек. Программаның төп максатлары

Программаның төп максатлары булып тора:

1) муниципаль хезмәт белән идарә итү системасын камилләштерү юлы белән җирле үзидарә органнары тарафыннан йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәттә кадрлар эшенә заманча технологияләр кертү.

## 4 бүлек. Программаның бурычлары һәм программа чараларының исемлеге

Куелган максатларны тормышка ашыру өчен түбәндәге бурычларны үтәргә кирәк:

1) оештыру структурасын һәм штат санын камилләштерү аша Башкарма комитет аппараты эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;

2) муниципаль хезмәткәрләрне сайлап алу, эшчәнлеген комплекслы бәяләү һәм хезмәт буенча күтәрүнең нәтиҗәле механизмнарын кертү

3) муниципаль хезмәткәрләрнең профессиональ һәм идарә компетентлылыгын үстерү;

4) муниципаль хезмәткә яшь, перспективалы белгечләрне җәлеп итү һәм беркетү;

5) муниципаль хезмәттә коррупциягә каршы тору чараларын тормышка ашыру системасын үстерү.

6) муниципаль хезмәттә мотивацияләү, стимуллаштыруның нәтиҗәле системасын төзү.

Муниципаль хезмәт системасын оештыру-методик һәм аналитик яктан тәэмин итүне формалаштыру түбәндәгеләр аша гамәлгә ашырыла:

1) муниципаль хезмәткәрләрне актуаль мәсьәләләр буенча методик материал белән тәэмин итү, муниципаль хезмәтнең ачыклыгы, һәркем файдалана алырлык булуы һәм аның абруен күтәрү;

2) муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Россия Федерациясе муниципаль

хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән тыюларның һәм чикләүләрнең үтәлүен контрольдә тотуны оештыру;

3) хезмәткәрләрнең персональ мәгълүматларын һәм хезмәткәрләр тарафыннан Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарында хезмәт эшчәнлеген (эшен) гамәлгә ашыру белән бәйле мәгълүматны саклау системасын тәэмин итү.

4) муниципаль хезмәткәрнең җәлеп итү образын формалаштыру.

Муниципаль хезмәт кадрларын әзерләү һәм аларның профессиональ үсеше өчен шартлар тудыру түбәндәге юл белән гамәлгә ашырыла:

1) муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрүне оештыру;

2) муниципаль хезмәткәрләрнең кыска сроклы тематик семинарларда катнашуын тәэмин итү;

3) җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәт өчен махсус кадрлар әзерләүне гамәлгә ашыручы югары уку йортлары белән хезмәттәшлек итү механизмын камилләштерү.

Кадрлар потенциалын тотрыклы үстерүне һәм муниципаль хезмәтнең нәтиҗәлелеген күтәрүне тәэмин итү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) муниципаль хезмәттә кадрлар потенциалын формалаштырганда заманча методларны куллану;

2) муниципаль хезмәттә хезмәт урынында үз-үзеңне тоту һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу механизмнарын формалаштыру һәм кертү;

3) муниципаль хезмәткәрне мораль һәм матди бүләкләү системасын камилләштерү;

4) муниципаль хезмәткәрләрнең эш урыннарын тәртипкә китерү һәм матди-техник җиһазландыруны модернизацияләү, муниципаль хезмәтнең нәтиҗәле үсеше өчен кирәкле матди-техник базаны ныгыту.

Программаны тормышка ашыру сроклары: 2018-2020 еллар.

Программаны тормышка ашыру этаплары:

1) 1 этап - 2018 ел;

2) 2 этап - 2019 ел;

3) 3 этап - 2020 ел.

## 5 бүлек. Программа чараларының исемлеге һәм кыскача тасвирламасы

Программа чараларының исемлеге һәм кыскача тасвирламасы 1 нче таблицада китерелгән

1 нче таблица

Программа кысаларында үткәрелә торган чаралар планы

| № | Чараның исеме | Башкаручылар |
|---|---|---|
| 1 | Муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре буенча тәкъдимнәр әзерләү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе |
| 2 | Җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын кертү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе |
| 3 | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының Бердәм мәгълүмат системасында кадрлар эшен алып баруны тәэмин итү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе,<br>Башкарма комитетның гомуми бүлеге |
| 4 | Яр Чаллы шәһәре рәсми сайтында һәм «Федераль дәүләт хезмәте һәм идарә кадрлары порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары турында мәгълүмат урнаштыру | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе |
| 5 | Массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтында муниципаль хезмәткәрләрнең эшчәнлеге турында мәгълүмат бастырып чыгару | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе |
| 6 | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт үтүгә бәйле таләпләр, чикләүләр һәм тыюлар, шул исәптән коррупциягә каршы тору буенча законнар үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе |

| | | |
|---|---|---|
| 7 | Муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрүне, яңадан һөнәри әзерлеген һәм стажировка узуын оештыру | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе |
| 8 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең идарә кадрлары резервын формалаштыру | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе |
| 9 | «2014-2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасы чаралары кысаларында Россиянең һәм чит илнең әйдәүче белгечләрен җәлеп итеп, семинарлар, киңәшмәләр, башка чаралар оештыруда катнашу | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе |
| 10 | «2014-2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасы кысаларында муниципаль хезмәткәрләрне укытуның нәтиҗәлелеге мониторингында катнашу | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе |
| 11 | «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль идарә өлкәсендә иң яхшы хезмәткәре» конкурсын оештыру һәм үткәрү һәм тиешле республика һәм бөтенроссия конкурсларында катнашуга тәкъдим итү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе |
| 12 | Муниципаль хезмәткәрләрне һәм җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен диспансеризацияләүне үткәрү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе |
| 13 | Муниципаль хезмәткәрләрнең эш урыннарын тәртипкә китерү һәм матди-техник җиһазлауны модернизацияләү | Башкарма комитетның гомуми бүлеге |

Программа чаралары өлешендә нәтиҗәлелекне бәяләү индикаторлары турында мәгълүматлар 2 нче таблицада китерелә

2 нче таблица

Программаның максатлары, бурычлары, чаралары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| № | Чараның исеме | Башкаручылар | Төп чаралар ны үтәү срок лары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2018 | 2019 | 2020 |
| | Максатның исеме: җирле үзидарә органнары тарафыннан йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү нәтиҗәлелеген арттыру | | | | | | | | | | |
| | Бурычның исеме: җирле үзидарә органнары аппаратлары эшчәнлегенең нәтиҗәләлеген арттыру | | | | | | | | | | |
| 1 | Муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре буенча тәкъдимнәр әзерләү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2018-2020 еллар | муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең формалаштырылган нәтиҗәлелек күрсәткечләре | - | - | + | - | - | - | - |
| 2 | Җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын кертү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2018-2020 еллар | җирле үзидарә органнарының җирле үзидарә органнары структурасы стандартларына туры китерелгән структуралары булу | | + | + | | - | - | - |
| 3 | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының Бердәм мәгълүмат системасында кадрлар эшен алып баруны тәэмин итү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе, Башкарма комитетның гомуми бүлеге | 2018-2020 еллар | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының Бердәм мәгълүмат системасында җирле үзидарә органнарының кадрлар составын характерлый торган актуаль мәгълүматлар булу | + | + | + | + | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Бурычның исеме: Муниципаль хезмәткәрләрне сайлап алу, эшчәнлеген комплекслы бәяләү һәм хезмәт буенча күтәрүнең нәтиҗәле механизмнарын кертү | | | | | | | | | | |
| 4 | Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында һәм «Федераль дәүләт хезмәте һәм идарә кадрлары порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары турында мәгълүмат | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2018-2020 еллар | муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары турында мәгълүмат булу:<br>1) муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында;<br>2) «Федераль дәүләт хезмәте һәм идарә кадрлары порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында | + | + | + | + | - | - | - |
| Бурычның исеме: Муниципаль хезмәткә яшь, перспективалы белгечләрне җәлеп итү һәм беркетү | | | | | | | | | | |
| 5 | Массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтында муниципаль хезмәткәрләрнең эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2018-2020 еллар | Массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында басылып чыккан мәкаләләр һәм башка мәгълүмати-аналитик материалларның саны | 8 | 10 | 12 | 15 | - | - | - |
| Бурычның исеме: Муниципаль хезмәттә коррупциягә каршы тору чараларын тормышка ашыру системасын үстерү | | | | | | | | | | |
| 6 | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт үтүгә бәйле таләпләр, чикләүләр һәм тыюлар, шул исәптән коррупциягә каршы тору буенча законнар үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2018-2020 еллар | Үткәрелгән тикшерүләр һәм башка чараларның саны | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Бурычның исеме: Муниципаль хезмәткәрләрнең профессиональ һәм идарә итү компетентлылыгын үстерү | | | | | | | | | | | |
| 7 | Муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрүне, яңадан һөнәри әзерлеген һәм стажировка узуын оештыру | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2018-2020 еллар | Тиешле елда квалификация күтәрү, яңадан профессиональ әзерлек үткән муниципаль хезмәткәрләрнең (1 елдан артык муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче) өлеше, штат саны % | 33 % | 33 % | 33 % | 33 % | 860,59 (муниципаль бюджет) | 860,59 (муниципаль бюджет) | 860,59 (муниципаль бюджет) |
| 8 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең идарә кадрлары резервын формалаштыру | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2018-2020 еллар | Җирле үзидарә органнарында идарә вазыйфаларына резервка кертелгән гражданнарның саны, кеше | 0 | 28 кеше | 28 кеше | 28 кеше | - | - | - |
| 9 | «2014-2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасы чаралары кысаларында Россиянең һәм чит илнең әйдәүче белгечләрен җәлеп итеп, семинарлар, киңәшмәләр, башка чаралар оештыруда катнашу | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2018-2020 еллар | муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча үткәрелгән белем бирү чаралары, семинарлар, киңәшмәләр, конференцияләр саны | 0 | 1 | 2 | 2 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 10 | «2014-2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасы кысаларында муниципаль хезмәткәрләрне укытуның нәтиҗәлелеге мониторингында катнашу | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2018-2020 еллар | «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясенә үткәрелә торган укытуның сыйфаты турында, муниципаль хезмәткәрләрне укыту системасын камилләштерү турында мәгълүмат җибәрү | 0 | 0 | 1 | 1 | - | - | - |
| Бурычның исеме: муниципаль хезмәттә мотивацияләү, стимуллаштыруның нәтиҗәле системасын төзү | | | | | | | | | | | |
| 11 | «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль идарә өлкәсендә иң яхшы хезмәткәре» конкурсын оештыру һәм үткәрү һәм тиешле республика һәм бөтенроссия конкурсларында катнашуга тәкъдим итү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2018-2020 еллар | муниципаль хокукый акт кабул итү һәм «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль идарә өлкәсендә иң яхшы хезмәткәре» конкурсын үткәрү | + | + | + | + | 100,0 (муниципаль бюджет) | 100,0 (муниципаль бюджет) | 100,0 (муниципаль бюджет) |
| 12 | Муниципаль хезмәткәрләрне һәм җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен диспансеризацияләүне үткәрү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2018-2020 еллар | җирле үзидарә органнарының диспансеризацияләү үткән муниципаль хезмәткәрләре һәм хезмәткәрләре саны, кеше | 320 | 400 | 400 | 400 | 655,94 (муниципаль бюджет) | 655,94 (муниципаль бюджет) | 655,94 (муниципаль бюджет) |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 13 | Муниципаль хезмәткәрләрнең эш урыннарын тәртипкә китерү һәм матди-техник җиһазлауны модернизацияләү | Башкарма комитетның гомуми бүлеге | 2018-2020 еллар | шартнамәләр булу һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеген мәгълүмати, административ-хуҗалык һәм матди-техник яктан тәэмин итүне оештыру | + | + | + | + | 2000,0 (муниципаль бюджет) | 2000,0 (муниципаль бюджет) | 2000,0 (муниципаль бюджет) |

## 6 бүлек. Муниципаль программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программа чаралары шәһәр бюджетының «Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары, җирле хакимиятләр эшчәнлеге» 01.04, «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 10849,59 мең сум: 2018 ел – 3616,53 мең сум, 2019 ел – 3616,53 мең сум, 2020 ел – 3616,53 мең сум күләмендә тормышка ашырыла.

## 7 бүлек. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программаны тормышка ашыру барышына контрольне Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе гамәлгә ашыра.

Программаның координаторы булып Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе тора.

Программаның координаторы, чираттагы финанс елына программаны тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган финанс средстволарын исәпкә алып, ел саен максатчан индикаторларны, программа чараларын тормышка ашыру чыгымнарын, программаны тормышка ашыру механизмын аныклый һәм программаны раслау турында норматив хокукый актка билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертә.

Программа чараларын башкаручылар, хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр, программаны тормышка ашыру турында программа координаторына мәгълүмат җибәрәләр.

Программаның координаторы программаны гамәлгә ашыруның, шулай ук финанс средстволарын файдалануның нәтиҗәлелеге турында белешмә һәм аналитик мәгълүматны гомумиләштерә.

Программаның нәтиҗәлелеген анализлау Башкарма комитетның 2013 елның 11 декабрендәге 7511 номерлы карары белән расланган Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова